СОВЕТ
БОЛЬШЕПОЛЯНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ЗУР ПОЛЯНКА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.03.2020 Зур Полянка авылы № 118

**Коррупциячел хокук бозуларны кылган өчен Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән «Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнары үтәлешен тикшереп торуны камилләштерү максатларында үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 3 августындагы 307-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында

**Зур Полянка авыл җирлеге Советы карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлеге советы карары белән расланган коррупциячел хокук бозулар кылган өчен Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлегенең 2015 елның 21 апрелендәге 153 номерлы муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турында нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр кертергә:

1.3. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә»;

2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Нигезләмәнең әлеге бүлегендә каралган дисциплиналы түләтүләр яллаучының (эш бирүче) вәкиле булган җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан нигезле рәвештә кулланыла:

коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы җирле үзидарә органының кадрлар бүлекчәсе (кадрлар хезмәте) тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад;

тикшерү нәтиҗәләре турындагы доклад әлеге комиссиягә юлланган очракта, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм җирле үзидарә органы мәнфәгатьләре конфликтын җайга салу комиссиясе тәкъдимнәре;

коррупциячел хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча доклады, анда аны башкаруның факттагы шартлары бәян ителә, һәм муниципаль хезмәткәрнең язмача аңлатмасы аның ризалыгы белән һәм коррупциячел хокук бозуны кылу фактын тану шарты белән (ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендә түләтүләр кулланудан тыш);

муниципаль хезмәткәрнең аңлатмалары;

башка материаллар.».

2. Әлеге карарны Зур Полянка авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлеге советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Зур Полянка авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **М.Р. Афанасьева**